# Татар теле дәресебезне башлыйбыз!

***Елмай! Бу дәрес сиңа да, дустыңа да шатлыклар китерсен!***

# *Сез нинди ел фасылларын беләсез?*

**Яз**

**Җәй**

**Көз**

**Кыш**






## *Текстны укыгыз.*

Салкын кыш килде. Кошлар җылы якка китәләр. Урамда ап-ак кар ява. Кояш кыздыра. Елгаларны калын боз каплады. Түбәдән тамчылар тама. Балалар биек тауда чана, чаңгы шуалар. Йомшак кардан кар бабай ясыйлар.

## *Сорауларга җавап бирегез.*

- Текстта нинди җөмләләр артык?
- Ни өчен?
- Кыш ел фасылына нинди җөмләләр туры килә? Шул җөмләләрне генә аерып укыгыз.

# КЫШ

Салкын кыш килде. Урамда ап-ак кар ява. Елгаларны калын боз каплады. Балалар биек тауда чана, чаңгы шуалар. Йомшак кардан кар бабай ясыйлар.

Салкын кыш килде. Урамда ап-ак кар ява. Елгаларны калын боз каплады. Балалар биек тауда чана, чаңгы шуалар. Йомшак кардан кар бабай ясыйлар.

Тексттан исемнәрне генә аерып әйтегез.

Тексттан сыйфатларны гына аерып әйтегез.

Тексттан фигыльләрне генә аерып әйтегез.

# Үзегезне тикшерегез!

Кемнәр? Балалар. Нәрсә? Кыш, кар, елга, боз, чана, чаңгы, кар, кар бабай.

Нинди? Салкын, ап-ак, калын, биек, йомшак.

Нишли? Ява, шуалар, ясыйлар. Нишләде? Килде, каплады.

# Рәсемгә карап җөмләләр төзегез.



## Күзләрне ял иттерегез.

Күзләр белән уңга, сулга, өскә, аска карагыз.

Күзләр белән түгәрәк, өчпочмак, квадрат ясагыз.

Тәрәзәгә еракка, якындагы предметка карагыз.

# **Мөстәкыйль эш.** ***Эшне тырышып эшләсәң, нәтиҗәсе яхшы була. Уңышлар сиңа!***

1. Нокталар урынына тиешле хәрефләрне куеп яз.

Ч...на, ча...гы, й...мшак, т...г...рәтә, тим...р...як, б...йрәм.

2. Нокталар урынына тиешле сүзләрне куеп җөмләләрне язып бетерегез.

1) ... шугалакта ... шуалар. 2) Җиргә ... һәм ... кар ява. 3) Балалар карны ... һәм шар ... .

3.Сообщи другу о том, что:

Ты хорошо катаешься на лыжах.

4. Диалогны язып бетер.

-Сәлам, Марат!

-... .

-Син тауга барасыңмы?

-... . ... ?

-Чаңгы шуабызмы?

-... .

Дәрестә нәрсәләр белдең?
Сиңа нәрсәләр авыр булды?
Син эшеңне ничек бәяләр идең?

***- Сез яхшы, акыллы балалар!***
***Көннәрегез уңышлы үтсен!***
***Сау булыгыз!***